ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.03.2020 ел Баулы шәһәре №46

Баулы муниципаль районы
территориясендә даими әзерлектә
булган эпизоотиягә каршы җыелма
мобиль отряд төзү турында

Россия Федерациясенең «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы (2019 елның 27 декабрендәге ред.) законы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон (2019 елның 26 июлендәге ред.) нигезендә, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы территориясендә даими әзерлектә булган эпизоотиягә каршы мобиль отряд булдырырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- 1нче кушымта нигезендә Баулы муниципаль районының даими әзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд (алга таба-Отряд) турында нигезләмәне;

- 2нче кушымта нигезендә отрядның оештыру-штат структурасын;

- 3нче кушымта нигезендә отрядның шәхси составы исемлеген;

- 4нче кушымта нигезендә отряд составына кертелгән техника исемлеген;

- 5нче кушымта нигезендә отрядның шәхси составына хәбәр итү схемасын;

- 6нчы кушымта нигезендә «Баулы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУнең отрядның әзерлегенә китерү буенча инструкциясе.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Баулы районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына йөкләргә (килешү буенча).

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты И.И. Гозәеров

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы
46 номерлы карарына
1нче кушымта

# БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ДАИМИ ӘЗЕРЛЕКТӘГЕ ЭПИЗООТИЯГӘ КАРШЫ ҖЫЕЛМА МОБИЛЬ ОТРЯДЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Баулы муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядны (алга таба – Отряд) оештыру һәм эшләтү тәртибен билгели.

1.2. Отряд штаттан тыш формирование булып тора һәм Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авырулар учакларына каршы көрәш һәм профилактика максатларында төзелә, һәм биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән.

1.3. Отряд үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең Баш дәүләт ветеринария инспекторы тарафыннан расланган биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләренә, Баулы муниципаль районы башлыгы боерыклары һәм карарларына, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмә буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең башка норматив-методик документларына таяна.

1.4. Отряд район дәүләт ветеринария берләшмәсе, Эчке эшләр бүлеге, шулай ук «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССО, торак-коммуналь хезмәт предприятиеләре, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы районнарында бүлеге, җирле үзидарә органнары вәкилләре һәм торак-коммуналь хуҗалык белгечләреннән формалаша.

1.5. Отрядның шәхси составы кирәкле профилактик вакцинацияне вакытында үтәргә тиеш.

## 2. Отряд бурычлары

2.1. Отряд кеше һәм хайваннар ечен уртак булган аеруча куркыныч авырулар учакларына каршы профилактика һәм көрәшү максатларында төзелә, һәм биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы һәм барлыкка килү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән.

2.2. Отрядның бурычлары этаплап билгеләнә:

беренче этап - авыруның төрен (яки хайваннар авыруының һәм үлеменең сәбәпләрен) билгеләгәнчегә кадәр;

икенче этап - авыру төре ачыклангannan һәм ахыргы диагноз куелганнан соң.

2.2.1. Беренче этапта отрядның бурычлары:

- ветеринария һәм медицина разведкаларын гамәлгә ашыру;
- эпидемиология һәм эпизоотик хәлне бәяләү;
- зәгыйфьләнгән һәм авыру хайваннарны (алга таба - авыру хайваннар) читләштерү;
- үлгән, авырый торган хайваннардан патологик материал алу;
- вирусологик тикшеренүләр һәм дифференциаль диагностика уздыру өчен махсус лабораторияләргә пробалар китерү;
- хайваннарны читләштергәннән соң җиһаз, инвентарь һәм бүлмәләрдә дезинфекцияләүне үткәрү;
- биналарны һәм территорияләрне механик рәвештә чистартып тору.

2.2.2. Отрядның икенче этабында бурычлары:

- карантин зонасында тәүлек буе үткәрү режимын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;
- карантин зонасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү;
- карантин зонасында урнашкан халык арасында профилактик һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;
- эпизоотик учакта барлык авыру хайваннарны аулау һәм юк итү;
– үлгән хайваннарны утильләштерү (юк итү) урыннарына илтү;
– үлгән хайваннарны утильләштерү;
- эпизоотик учакны бетерүдә катнашучы отрядның һәм башка затларның шәхси составын санитар эшкәртү;
– бер тапкыр кулланыла торган саклану чараларын юк итү;
- дезинфекция буенча барлык чаралар комплексын үткәрү;
- хайваннарны һәм башка мөлкәтне алуны раслый торган документлар әзерләү һәм аларны милекчеләргә законнарда билгеләнгән компенсация түләүләрен алу өчен бирү;
- хисап алу, утильләштерү, юк итү нәтиҗәләре буенча беренчел хисап документларын (актларны) төзү;
– хайваннар авыруларын профилактикалау һәм эпизоотик учакны бетерү чаралары

турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка хәбәр итү.

3. Отряд бүлекчәләренең оештыру структурасы, бурычлары һәм җиһазландырылуы

3.1. Отрядның командиры һәм шәхси составы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә. Отрядның командиры - район дәүләт ветеринария берләшмәсе начальнигы.

3.2. Отряд төп бүлекчәләрдән һәм тәэмин итү бүлекчәләреннән тора.

Теп бүлекчәләр:

- ветеринария разведкасы теркеме;
- хайваннарны тоту һәм үтерү төркеме;
- кыргый хайваннарның (кошларның) санын кейләүче теркем;
- утильләштерү теркеме;
- дезинфекция төркеме.

Тәэмин итү бүлекчәләре:

- медицина һәм эпидемиология разведкасы теркеме;
- үткәрү режимын тәэмин итү теркеме;
– җәмәгать тәртибен саклау төркеме;
– табиб-шәфкать туташлары бригадасы;
- янгын бүлекчәсе;
- санитар-юдыру пункты

3.3. Ветеринария разведкасы төркеме үлгән (авыручы) хайваннарны ачыклау (табу) урынына чыгып, патологик материал сайлап алуны (кан алу, патологик материал һәм биоматериалны сайлап алу тәртибе буенча инструкция нигезендә), аны махсуслаштырылган лабораториягә илтүне (тикшеренү өчен пробалар бирү тәртибе нигезендә) һәм үлгән хайваннарны ачыклау (ачыклау) урынына янәшәге ишегалларны һәм территорияләрне әйләнеп чыгуны (тикшерүне) башкара, һәлак булган хайваннарны исәпкә алуны алып бара.

Ветеринария разведкасы төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе хезмәткәрләреннән формалаша. Ветеринария разведкасы төркеме командиры – отряд командиры урынбасары.

Ветеринария разведкасы төркеменең шәхси составы шәхси саклану костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: авыру хайваннарны тоту өчен кирәк-яраклар, патологик материалны алу өчен махсус инструментлар, патологик материалны транспортлау өчен кирәк булган термоконтейнер, лабораториягә патологик материал юнәлешләренең бланклары, мобиль элемтә чаралары, полиэтилен капчыклар, дезинфекция чаралары, су

(5 литрдан да ким түгел), кул юу өчен савытлар, сөлге, сабын, бинокль, фонарь, һәлак булган хайваннарны (кошларны) исәпкә алу журналы.

3.4. Авыру хайваннарны тоту һәм юк итү төркеме авыру хайваннарны аулый,кирәк булган очракта аларга эвтаназия үткәрә, аларны җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар күрә, үлгән хайваннарны исәпкә ала, хайваннарны алу, юк итү буенча документлар әзерли. Хайваннарны тоту һәм юк итү төркеме район ветеринария берләшмәсе, торак-коммуналь предприятиеләр хезмәткәрләреннән формалаша.

Төркемнең шәхси составы шәхси саклану костюмнары һәм сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Теркемне җиһазлау: хайваннарны тоту ечен кирәк-яраклар, полиэтилен капчыклар, хайваннарны йоктыру өчен чаралар, шприц-автоматлар, үлгән хайваннарны исәпкә алу журналы, актлар бланклары һәм дезинфекция чаралары.

3.5. Утильләштерү теркеме утильләштерү урынын әзерли, үләксәләрне утильләштерү урынында бушата, дезинфекция чараларын кулланып, биотермик чокырларда хайван үләксәләрен утильләштерә яки янгын куркынычсызлыгы һәм шәхси куркынычсызлык чараларын катгый үтәгәндә яндыру юлы белә утильләштерелә, утильләштерелгән хайваннарны исәпкә ала.

3.5. Кыргый хайваннарның (кошларның) санын кейләү төркеме кыргый фаунада контактлы яки авыру хайваннарны (кошларны) атуны (атуны) гамәлгә ашыра, аларны җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар уздыра, атылган, һәлак булган хайваннарны (кошларны) исәпкә ала һәм аларны лаборатор тикшеренүләргә китерә.

Төркем Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының район (районара) бүлеге хезмәткәрләреннән (килештерү буенча) төзелә.

Теркемнең шәхси составы сулыш һәм тире органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Теркемне җиһазлау: чехолдагы ау мылтыгы, ау пычаклары, амуниция (патронташ, кейслар һ.б.), тоту ечен ятьмә, хайваннар (кошлар) үләксәләре өчен полиэтилен капчыклар, атылган кыргый хайваннарны (кошларны) исәпкә алу журналы.

3.6. Утильләштерү төркеме утильләштерү урынын әзерли, үләксәләрне утильләштерү урынында бушата, дезинфекция чараларын кулланып, биотермик чокырларда хайван үләксәләрен утильләштерә яки янгын куркынычсызлыгы һәм шәхси куркынычсызлык чараларын катгый үтәп, үләксәләрне яндыра утильләштерелә, утильләштерелгән хайваннарны исәпкә ала.

Утильләштерү төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе, гражданнар оборонасының коммуналь-техник хезмәте хезмәткәрләреннән формалаша.

Утильләштерү төркеме составыннан ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясе ветеринария табибы терлек чалу продуктларына ветеринариясанитария бәяләмәсен уздыра.

Теркемнең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Теркемнең җиһазланышы: экскаватор һәм металл кузовлы йөк автомобиле (яки металл сыешлы автомобиль), дезинфекция чаралары, утильләштерелгән хайваннарны исәпкә алу журналы.

3.7. Дезинфекция теркеме авыруларны ачыклау урынын механик чистарту, йогышлы учакның агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясен (ветеринария дезинфекциясе, дезинвазия, дезинсекция һәм дератизация уткәрү инструкциясе нигезендә) уткәрә. Дезинфекция төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе һәм торак-коммуналь хуьалык хезмәткәрләреннән формалаша.

Төркемнең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Теркемнең җиһазланышы: Комаровның дезинфекция җайланмасы һәм дезинфекция чаралары.

3.8. Медицина һәм эпидемиология разведкасы теркеме гамәлгә ашыра:

- эпидемия учагында медицина һәм санитар-эпидемиологик разведка һәм күзәтчелек;

- хәвеф төркемендәге затларга (хуҗалык хезмәткәрләрен, эпизоотия учагын бетерүдә катнашкан отрядның һәм башка катнашучыларның шәхси составы) медицина тикшерүе уткәрү;

– авыруларны ачыклау максаты белән ишегалларны йөреп чыгу һәм авырулар белән аралашучыларны һәм контакт дәрәҗәсен билгеләү;

– Республиканың махсуслаштырылган лабораторияләренә лаборатор тикшеренүләр өчен материалны сайлап алу һәм китерү;

– ашыгыч профилактикалау һәм ашыгыч профилактиканы оештыру һәм уткәрүне контрольдә тоту;

– авыруларны, авыруга шик булган затларны вакытлыча изоляцияләү;

- эпидемия учагында агымдагы һәм йомгаклау йогышсызландыруны уткәрү һәм контрольдә тоту.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССОның, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы районнары бүлеге хезмәткәрләреннән формалаша.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеменең шәхси составы саклау

костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеменең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

3.8. Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме карантин зонасында хәрәкәтне оештыра һәм җайга салуны тәэмин итә. Төркем контроль-пропуск постларыннан һәм патрульпост хезмәте постларыннан тора. Постлар саны карантин зонасына керү (чыгу) саны белән билгеләнә.

Төп керү урыннарында (карантин зонасына) контроль-пропуск постлары, икенче урында – патруль-пост хезмәте постлары булдырыла.

Пропуск режимын тәэмин итү төркеме район эчке эшләр бүлеге, юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе, район дәүләт ветеринария берләшмәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан формалаша (килешү буенча).

Контроль-пропуск постын җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, дезинфекция барьеры, шлагбаум, кешеләрне киендерү урыны, Комаров дезинфекцияләү җайланмасы яки транспорт чараларын юу һәм дезинфекцияләү өчен махсус техника, эш эремәсен әзерләү савыты, су савыты, дезинфекция чаралары, юдыргыч, сөлге, сабын, "Карантин" язуы.

Патруль-пост хезмәте постын җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, шлагбаум, "Карантин" язуы, карантин зоналарын урап үтү юлын күрсәтә торган юл билгеләре, фонарь.

Үткәрү режимы теркеменең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, итекләр, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

3.10. Җәмәгать тәртибен саклау төркеме карантин зонасында хокук тәртибен саклауны тәэмин итә, отрядның шәхси составын, беренче авыруатта, хайваннарны тоту һәм юк итү теркемнәрен, медицина һәм эпидемиология разведкасы төркемнәрен озатып баруны һәм саклауны оештыра.

Җәмәгать тәртибен саклау теркеме район эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләреннән формалаша.

Төркемнең шәхси составы корал һәм саклану штат чаралары белән тәэмин ителә һәм җиһазландырыла.

3.11. Табиб-шәфкать туташлары бригадасы карантин-чикләү чараларын уздыру чорында халыкка кичектергесез медицина ярдәме күрсәтә, ачыкланган авыруларны йогышлы авырулар бүлегенә госпитализацияләүне оештыра.

Табиб-шәфкать туташлары бригадасы «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССОның хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Бригаданың шәхси составы саклагыч костюмнар, халатлар, баш кием-салым һәм битлекләр белән тәэмин ителә.

Бригаданы җиһазлау: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының җитәкче документлары таләпләре нигезендә табиблар урнаштыру урыны һәм башка табель мелкәте.

3.12. Янгын бүлеге үлгән хайваннарны яндырганда янгын куркынычсызлыгы чаралары үтәлешен тикшерә.

Бүлекчә командиры яндыру урынын сайлауда катнаша. Янгын чыккан очракта аны сүндерүне оештыра һәм үткәрә.

Янгын расчеты Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 11 янгын сүндерү һәм коткару бүлегенең 109нчы янгын-коткару часте хезмәткәрләреннән формалаша.

3.13. Санитар-юдыру пункты шәхси составка һәм милеккә санитар эшкәртү үткәрә.

Санитар-юдыру пунктының шәхси составы торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Хайваннар һәм кешеләр авыруларын локальләштерү һәм бетерү буенча чаралар комплексы тәмамланганнан соң, отрядның шәхси составы һәм карантин зонасында эшкә җәлеп ителгән затлар мәҗбүри санитар эшкәртү уза, ә бер тапкыр кулланыла торган махсус кием яндыру юлы белән юк ителә.

Пунктны җиһазлау: Комаровның дезинфекция җайланмасы (күчмә душ җайланмалары яки ранецлы дезинфекцион сиптергечләр), су савыты, сабын, сөлге, утын.

## 4. Отряд командиры вазыйфалары

4.1. Отряд командиры эпидемия учагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм үткәрү, отрядны шәхси состав һәм мөлкәт белән комплектлау, әзерлек, дисциплина, бурычларны вакытында һәм тиешенчә үтәү ечен җавап бирә һәм йогышлы авырулар чыганагын бетерү буенча бурычларны үтәү чорында отрядның барлык шәхси составының турыдан-туры башлыгы булып тора.

Отряд командиры Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

4.2. Отряд командиры бурычлы:

– инфекция үзәгендә эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм алып бару буенча җитәкче документларның таләпләрен белү һәм үз эшчәнлегендә аларга таянырга;

- отрядның шәхси составының функциональ бурычларын эшләүдә һәм корректировкалауда катнашу;

- үзенә йөкләнгән бурычларны үтәгәндә отрядның шәхси составы белән җитәкчелек итәргә; отрядның шәхси составын, аның бурычларын, шәхси составны комплектлау мөмкинлекләрен, тәртибен, техника һәм мөлкәтнең барлык төрләре белән җиһазланышын белергә;

- хезмәткәрләрнең эпизоотияне булдырмау һәм бетерү буенча махсус әзерлек дәрәҗәсен, мораль һәм эшлекле сыйфатларын белергә;

- отрядның урнашу һәм эш итү районындагы ветеринария-санитария һәм эпизоотия торышын өйрәнү;

- эпизоотик учакны локальләштерү һәм бетерү вакытында отрядны җыю һәм эшен җәелдерү урыннарын белергә;

- отрядның учактагы хәрәкәтләргә әзерлеген арттыру һәм эшен камилләштерү буенча чаралар әзерләргә һәм оештырырга;

- отрядның әзерлеген арттыру буенча чаралар үткәрергә, шәхси составның даими әзерлегенә ярдәм итәргә;

- куелган бурычларны үтәүгә ирешү, акыллы инициатива күрсәтү һәм карарлар кабул итү;

- милекне һәм махсус техниканы дөрес файдалануны, карап тотуны һәм саклауны контрольдә тоту;

- отрядның шәхси составын шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү;

- үлгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү урыннарын җирле үзидарә органнары белән килештерергә;

- шәхси составны санитар эшкәртү, эшләр (чаралар) тәмамланганнан соң техника, мөлкәт һәм җиһазларны дезинфекцияләүне оештырырга;

- гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча оператив штабка (эпизоотия) учакны локальләштерүгә һәм бетерүгә җәлеп ителә торган кечләрнең һәм чараларның составы, эпизоотиянең торышы, эшләрнең (чараларның) барышы турында мәгълүматны үз вакытында тапшырырга;

- эшләрне (чараларны) үткәрү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составын үзгәртү буенча үз вакытында карарлар кабул итәргә, аларны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән килештерергә;

- Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба - КЧС һәм ОПБ) Рәисенең эпизоотияләр аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр режимнарын кертү турында карарын эшләү өчен тәкъдимнәр тапшырырга;

- отряд бүлекчәләренең ихтыяҗларын билгеләү һәм бүлү һәм техника, матди, дезинфекция һәм башка чаралар белән тәэмин итүгә үз вакытында гариза бирү;

- матди чараларны исәпкә алу, саклау һәм куллануны оештырырга һәм контрольдә тотарга;

- отрядның шәхси составы белән елга кимендә бер тапкыр өйрәнүләр үткәрергә;

- отрядның шәхси составы өчен куркынычсызлык таләпләрен билгеләргә һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга, эшләрне (чараларны) үткәргәндә аларның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә һәм башка югары органнарга, идарәләргә үткәрелгән чаралар турында хисаплар җиткерергә.

5. Отрядны әзерлеккә китерү тәртибе

5.1. Отряд Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карары буенча әзерлеккә китерелә.

5.2. ГТХ (карантин) зонасында эшләү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составын отряд командиры тәкъдиме белән Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе билгели, һәм гадәттән тыш хәлгә китергән авыру теренә (аеруча куркыныч инфекция) һәм башкарыла торган бурычлар күләменә бәйле.

5.3. Отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю өчен «Баулы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУның кизү тору инструкциясе (әлеге карарга 5нче кушымта) эшләнә һәм раслана.

5.4. Сигнал алу мизгеленнән әзерлеккә китерү ечен гомуми вакыт тәшкил итә:

эш вакытында: отряд-2 сәгатьтән дә артык түгел, ветеринария разведкасы Теркеме-бер сәгатьтән дә артык түгел;

эш булмаган вакытта: отряд-4 сәгатьтән дә артык түгел, ветеринария разведкасы төркеме - 2 сәгатьтән дә артык түгел.

5.5. Бүлекчәләрнең (төркемнәрнең) командирлары җыелу урынына килеп җитү белән моның турында отряд командирына хәбәр итәләр, табельле милек һәм шәхси саклану чаралары бирүне һәм алуны оештыралар, отряд командирына бурычларны үтәүгә әзерлек турында хәбәр итәләр.

Сигнал алу мизгеленнән әзерлеккә китерү өчен гомуми вакыт:

эш вакытында: отряд - 2 сәгатьтән дә артык түгел, ветеринария разведкасы төркеме - бер сәгатьтән дә артык түгел;

эш булмаган вакытта: отряд - 4 сәгатьтән дә артык түгел, ветеринария разведкасы теркеме - 2 сәгатьтән дә артык түгел.

6. Отрядның эш режимнары

Баулы муниципаль районы территориясендәге биологик (ветеринария, эпизоотик) хәлгә карап, отряд өчен түбәндәге эш режимнарының берсе билгеләнә:

югары әзерлек режимы - хайваннарның (кошларның) үлүе ачыкланган мизгелдән диагноз куелганчыга кадәр (үтәлә торган бурычларның беренче этабына туры килә);

биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәл режимы (алга таба - эпизоотия режимы) - авыру буенча аларның имин булмавы һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә аерым территорияләрдә чикләү чаралары (карантин) билгеләү белән (алга таба - эпизоотия режимы).

7. Отрядның шәхси составын әзерләү

7.1. Отрядка кергән белгечләр штаттагы вазифалар буенча эшләү тәҗрибәсенә ия булырга тиеш.

7.2. Отрядның шәхси составын әзерләүнең төп методлары булып инструкторлык-методик дәресләр, гамәли күнекмәләр өйрәнү тора.

7.3. Шәхси состав белән инструкторлык-методик дәресләрдә эпизоотик учакта эшләгәндә шәхси составның йогышлы авыруларын кисәтү, шәхси саклану чараларыннан файдалану кагыйдәләренә, шулай ук кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авыруларга каршы көрәш чаралары турында инструкция таләпләрен һәм әлеге нигезләмә таләпләрен җиткерүгә аерым игътибар бирелә.

7.4. Отрядның шәхси составы белән инструкторлык-методик дәресләрне бүлекчә командирлары үткәрә. Күнекмәләрне әзерләү, үткәрү өчен отряд командиры җавап бирә.

7.5. Отрядның шәхси составын әзерләү өчен Отряд командиры За подготовку личного состава Отряда отвечает командир Отряда.

8. Отрядның матди-техник һәм финанс тәэмин ителеше

Отрядның матди-техник һәм финанс тәэмин ителеше отрядның тиешле функциональ бүлекчәләрен (теркемнәрен) формалаштыручылар һәм Баулы муниципаль районы бюджеты чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

Отряд командиры карары нигезендә, көндәлек эшчәнлектә кулланылмый торган һәм эпизоотия режимында эшләү өчен билгеләнгән приборлар, лаборатория җиһазлары, реактивлар, саклану чаралары, дезинфекция чаралары һәм башка чаралар запасы махсус биналарда саклана, тезек хәлдә тотыла һәм билгеләнгән тәртиптә яңартыла.

9. Отряд документлары исемлеге

9.1. Һәр отрядта отряд командирында булган документларның мәҗбүри исемлеге формалаша.

9.2. Отрядның документациясен алып бару, документлардагы белешмәләрне дерес рәсмиләштерү һәм вакытында төгәлләштерү өчен отряд командиры җавап бирә.

9.3. Отряд документлары исемлеге:

- даими әзерлектә булган эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд булдыру һәм комплектлау турында Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары күчермәсе;

- даими әзерлектә булган эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд булдыру һәм комплектлау турында Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары күчермәсе;

- отрядның оештыру-штат структурасы;

- отрядның шәхси составы исемлеге;

- отряд составына кертелгән автомобиль һәм махсус техника исемлеге;

- отрядның шәхси составына хәбәр итү схемасы;

- «Баулы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУнең кизү торучысы тарафыннан отрядның шәхси составын әзерлеккә китерү буенча инструкция.

9.4. Шәхси состав буенча мәгълүматны төгәлләштерү (корректировкалау) ярты елга кимендә бер тапкыр, шулай ук өйрәнүлә, һәм оештыру-штат чаралары алдыннан үткәрелә.

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр белән идарә итүчесе — Х.С. Мөгыйнов

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы
46 номерлы карарына
2нче кушымта

## Баулы муниципаль районы даими әзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының оештыру-штат структурасы

О

Командир – (РГВО житәкчесе) - 1 кеше
жиңел автомобиль – 1 берәмлек

Ветеринария разведкасы төркеме:
- командир - 1 кеше.
- лаборант – 1 кеше.
- шофер - 1 кеше.
жиңел автомобиль – 1 берәмлек.

Кыргый хайваннарның һәм кошларның санын көйләү төркеме:
- төркем командиры - 1 кеше.
- аучы – 2 кеше.

Кыргый хайваннарны тоту һәм юк итү төркеме:
- төркем командиры - 1 кеше.
- машина йөртүче - 1 кеше.
- аучы – 1 кеше.
- санаучы (ЦБ)– 1 кеше.
- финанс органы вәкиле (ФБП) - 1 кеше.
йөк автомобиле – (КТС) - 1 берәмлек.

**Утильләштерү төркеме:**
**- төркем командиры (КХВ) – 1 кеше.**
**- утильләштерүче (КТС) - 4 кеше.**
**- машина йөртүче-экскаваторчы (КТС) -1 кеше.**
**- санаучы (ЦБ) – 1 кеше.**
**– санитар ветеринар. эксперт – (РГВО) - 1 кеше.**
**- йөк автомобиле йөртүчесе (КТС) – 1 кеше.**
**йөк автомобиле-1ед.**

**Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме:**
**- төркем командиры (ЦРБ табибинфекционисты) - 1 кеше.**
**- табиб ярдәмчесе (ЦРБ) – 1 кеше.**
**- гомуми гигиена буенча табиб – 1 кеше**
**- фельдшер (ЦРБ) – 1 кеше.**
**- машина йөртүче (ЦРБ) - 1 кеше.**
**жиңел автомобиль – 1 берәмлек.**

**Дезинфекция төркеме:**
**- командир – РГВОның табибэпизоотологы) - 1 кеше.**
**- лаборант – (РГВО ветеринары) - 1 кеше.**
**- дезинфекцияләүче – (СЭС) - 1 кеше.**
**- машина йөртүче-дезинфектор (РГВО) - 1 кеше.**
**Комаровның дезинфекция жайланмасы – 1 берәмлек**

**Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме:**
**- төркем командиры (ОМВД) – 1 кеше.**
**- көйләүче (ОМВД) – 1 кеше.***
**- дезинфектор (РГВО)-1 кеше.**
**-машина йөртүче дезинфектор – 1 кеше**
**патруль-пост хезмәте автомобиле-1 берәмлек.***
**автомобиль – (РГВО) - 1 берәмлек.**
**күчмә дезинфекцияләүче жайланма-1 берәмлек.**
*** - керү-чыгуга карап**

**Җәмгать тәртибен саклау төркеме:**
**- төркем командиры (ОМВД) – 1 кеше.**
**– Эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре (ОМВД) - 5 кеше.**
**- машина йөртүче – 2 кеше.**
**Автомобиль - 2 берәмлек.**

**Санитар-юдыру пункты:**
**- пункт командиры (КХВ) – 1 кеше.**
**-кочегар – 1 кеше.**
**- машина йөртүче - 1 кеше**
**- Комаровның дезинфекцияләү жайланмасы – 1 бер.**
**Душ керү жайланмасы - 1 бер.**

**Табиб-шәфкать туташлары бригадасы:**
**- бригада командиры (ЦРБ табибе) – 1 кеше.**
**- фельдшер (ЦРБ) – 1 кеше.**
**- шәфкать туташы (ЦРБ) – 1 кеше.**
**- машина йөртүче (ЦРБ) - 1 кеше.**
**санитар автомобиль - 1ед.**

**Янгын буенча:**
**– бүлекчә командиры (ДПО) - 1 кеше.**
**– янгын сүндерүче (ДПО) - 3 кеше.**
**-машина йөртүче – 1кеше**
**Янгын сүндерү машинасы (ДПО) –1ед.**

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы
46 номерлы карарына
3нче кушымта

Баулы муниципаль районы даими әзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының шәхси составы исемлеге

| /п | Оешма исеме<br><br>Татарстан Республикасында | Количество выделяемых людей |
|---|---|---|
| . | "Баулы үзәк район хастаханәсе" ДАСУ | 4 |
| . | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге | 10 |
| . | Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсенең 11нче янгынга каршы хезмәтенең 109нчы янгын-коткару бүлеге. | 5 |
| . | “Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге" ФБССО Бегелмә, Азнакай, Баулы районнарында бүлеге | 3 |
| . | Баулы шәһәре “Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» муниципаль казна предприятиесе | 7 |
| . | «Комфорт» ЖЧЖ | 1 |
| . | Баулы муниципаль районының “Водоканал" Муниципаль казна предприятиесе | 7 |
| | Барлыгы: | 37 |

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитетының Эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы
46 номерлы карарына
4нче кушымта

Баулы муниципаль районының эпизоотиягә каршы даими әзерлек буенча җыелма мобиль

отряд составына кертелгән техника исемлеге

| п/п | Автомобиль һәм махсус техника тибы | Техника каян бирелә (оешма исеме) | Количество техники, ед. |
|---|---|---|---|
| | УАЗ, Лада Ларгус, Комаров дезинфекция җайланмасы | "Баулы район дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ | 3 |
| | Юл-патруль хезмәте автомобиле | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| . | Йөк автомобиле, экскаватор, трактор, Камаз, водовоз | Баулы шәһәре “Тезекләндерү һәм яшелләндерү буенча идарә» МКП | 5 |
| . | Fiat Dukato | "Баулы үзәк район хастаханәсе" ДАСУ» | 1 |
| . | Renault Logan | “Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге" ФБССО Бегелмә, Азнакай, Баулы районнарында бүлеге | 1 |
| . | Зил 433114 | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 109нчы янгын-сүндерү һәм коткану часте | 1 |
| . | УАЗ | “Комфорт” ЧҖҖ | 1 |
| . | Камаз, канал юу машинасы | БМР «Водоканал» МКП | 2 |
| | Барлыгы: | | 15 |

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мегыйнов

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы

46 номерлы карарына
5нче кушымта

## Баулы муниципаль районы даими әзерлек отрядының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль составына хәбәр итү схемасы




Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы
46 номерлы карарына
6нче кушымта

"Баулы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУнең дежурныеның Баулы муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядны даими әзерлеккә китерү буенча инструкциясе

1. Баулы муниципаль районының эпизоотиягә каршы даими әзерлектәге җыелма мобиль отрядын (алга таба – Отряд) әзерлеккә китерү Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе яки аны алмаштыручы зат карары буенча башкарыла.

2. «Баулы район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ кизү торучысы (күрсәтмә) отрядны әзерлеккә китерү турында күрсәтмә алгач, журналда алынган мәгълүматның датасын һәм вакытын, мәгълүматны тапшырган шәхси мәгълүматларын (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен), кыскача эчтәлеген, элемтә өчен телефон номерын теркәргә һәм шунда ук бу хакта отряд командирына хәбәр итәргә тиеш.

3. Отряд командиры отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю буенча күрсәтмә бирә.

4. Дежурный шәхси составка Баулы муниципаль районының эпизоотиягә каршы даими әзерлек җыелма мобиль отрядының шәхси составына хәбәр итү схемасы буенча хәбәр итә (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы даими әзерлек җыелма мобиль отрядын төзү турында» 2020 елның 13 мартындагы 46нчы карарына 5нче кушымта).

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр белән идарә итүчесе — Х.С. Мөгыйнов